КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 29 май г.Казань № 754

Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә спорт ярышларын уздырганда су объектларыннан файдалану турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 статьясының 4 өлеше һәм 25 статьясының 1 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 23 апрель, 256 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләренең 1.3 пункты нигезендә, Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә спорт ярышлары (15 – 17 яшьтәге яшүсмер егетләр һәм кызлар арасында триатлон буенча Россия беренчелеге) уздырганда кешеләрнең тормыш куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларындаТатарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ :

1. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

Казансу елгасында Кремль дамбасыннан алып «Компрессор күпер» өченче транспорт дамбасына кадәр участокта аз үлчәмле, йөрүче, спорт-җилкәнле судноларны куллануны тыярга (алга таба - тыю):

2026 елның 11 июнендә 14.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр,

2026 елның 12 июнендә 06.00 сәгатьтән 15:00 сәгатькә кадәр,

2026 елның 13 июнендә 06.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр,

2026 елның 14 июнендә 06.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр;

тыюның спорт ярышларын әзерләү, уздыру һәм аларда катнашу өчен җәлеп ителгән судноларга кагылмавын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

тыюны гамәлгә ашыру максатларында күрсәтелгән участокларда көчләрнең һәм чараларның кизү торуын тәэмин итәргә;

тыю турында халыкка хәбәр итү эшен оештырырга, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша да.

3. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә тыюны үтәү максатларында көчләрнең һәм чараларның кизү торуын тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин